Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

21.02.2024 Менделеевск ш. №120

"Сәнәгать-җитештерү тибындагы«Алабуга»
махсус икътисади зонасы" акционерлык җәмгыятенең
2024-2026 елларга "Менделеевск муниципаль районының
коммуналь техник су белән тәэмин итү системасын үстерү,
реконструкцияләү һәм модернизацияләү
инвестицион программасына
төзәтмәләр кертүгә техник йөкләмәне
раслау турында.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карары белән расланган «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты, кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын эшләү, килештерү, раслау һәм төзәтү кагыйдәләренең 33 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты "Сәнәгать-җитештерү тибындагы«Алабуга» махсус икътисади зонасы" акционерлык җәмгыятенең мөрәҗәгатен карап,

КАРАР БИРӘ:

1. «Менделеевск муниципаль районының коммуналь техник су белән тәэмин итү системасын үстерү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү "Сәнәгать-җитештерү тибындагы«Алабуга» махсус икътисади зонасы" акционерлык җәмгыятенең 2024-2026 елларга инвестиция программасына төзәтмәләр кертү буенча техник йөкләмәне расларга.

2. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә өч эш көне дәвамында « "Сәнәгать-җитештерү тибындагы«Алабуга» махсус икътисади зонасы" акционерлык җәмгыятенең инвестиция программасын төзәтмәләр кертү проектын эшләү өчен расланган карарны җибәрергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгына йөкләргә.

| | |
|---|---|
| Җитәкче | Р.Р. Искәндәров |

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН:

| | |
|---|---|
| Җитәкченең беренче урынбасары | А.Ф. Искаков |
| ТР ММР эшләре белән идарә итүче | Е.И. Нәгыймова |
| Юридик бүлек башлыгы | Е.С. Царёва |

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 21 февралендәге
120 номерлы
карарына кушымта

«Менделеевск муниципаль районының коммуналь техник су белән тәэмин итү системасын үстерү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү "Сәнәгать-җитештерү тибындагы«Алабуга» махсус икътисади зонасы" акционерлык җәмгыятенең 2024-2026 елларга инвестиция программасына төзәтмәләр кертү буенча техник бирем

1 Менделеевск муниципаль районының 2024-2026 елга үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасы (техник су белән тәэмин итү һәм (яисә) су бүлеп бирү объектларын реконструкцияләү һәм модернизацияләү буенча инвестиция программасына төзәтмәләр кертүченең заказ бирүчесе булып (алга таба - Программа) Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты тора.

Программага төзәтмәләр кертүне эшләүче - "Сәнәгать-җитештерү тибындагы«Алабуга» махсус икътисади зонасы" акционерлык җәмгыяте

2 Программага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 Коммуналь техник су белән тәэмин итү системасын реконструкцияләргә кирәк булган капиталь төзелешнең гамәлдәге объектларын кертергә.

| № т/б | Капиталь төзелеш объекты исеме | Техник характеристикалар | Гамәлгә ашыру елы |
|---|---|---|---|
| Турай су җыю объектларын реконструкцияләү | | | |
| 1 | Насос станциясе I - күтәрелү (юдыру камерасын реконструкцияләү | | |
| | Техник су белән тәэмин итү | 13х4 | 2025 |
| 2 | насос агрегатларының суырты линиясен реконструкцияләү | | |
| | Техник су белән тәэмин итү | 1 000 ду | 2025 |

3 Программага төзәтмәләр кертүнең нәтиҗәсе - гамәлдәге законнар таләпләрен үтәү, Менделеевск муниципаль районы үзәк су белән тәэмин итү объектларының (техник су һәм (яисә) су бүлеп бирү объектларының ышанычлылыгы, энергия нәтиҗәлелеге сыйфатының расланган план күрсәткечләренә ирешү.

4 Программаны корректировкалау проектын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карары белән расланган оешмаларны кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм

(яисә) су агызуны гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын әзерләү, килештерү, раслау һәм корректировкалау кагыйдәләренең IV бүлеге тарафыннан билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырырга.